ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 февраль 2019ел. № 1039

Башкарма комитетның «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 5526 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамә, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 5526 нчы карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 6 декабрендәге 7547 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 нче карары белән» сүзләрен «Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктта «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 11427,84 мең сум күләмендә: 2018 елда – 3809,28 мең сум, 2019 елда – 3809,28 мең сум, 2020 елда – 3809,28 мең сум» сүзләрен «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 11302,98 мең сум күләмендә: 2018 елда – 3684,42 мең сум, 2019 елда – 3809,28 мең сум, 2020 елда – 3809,28 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

3) «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары (мең сум) | | | Барлыгы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | |
| | муниципаль бюджет | 3 684,42 | 3 809,28 | 3 809,28 | 11302,98 |
| | республика бюджеты | - | - | - | - |
| | федераль бюджет | - | - | - | - |
| | башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | барысы | 3 684,42 | 3 809,28 | 3 809,28 | 11302,98 |

- 4 бүлекнең 14 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем алуын оештыру;»;

- 5 бүлектәге 1 нче таблицаның 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 7 | Муниципаль хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем алуын оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |

- 5 бүлектәге 2 нче таблицаның 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Муниципаль хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем алуын оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | тиешле елда квалификация күтәрү, һөнәри әзерлек үткән муниципаль хезмәткәрләрнең (муниципаль хезмәт вазыйфасын 1 елдан артык биләгән) өлеше, штат санының % | 33% | 33% | 33% | 33% | 1095,67 (муниципаль бюджет) | 1053,34 (муниципаль бюджет) | 1053,34 (муниципаль бюджет) |

- 5 бүлектәге 2 нче таблицаның 11, 12, 13 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендәге иң яхшы хезмәткәре» конкурсын оештыру һәм үткәрү һәм республика һәм бөтенроссия конкурсларында катнашуга тәкъдим итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | муниципаль хокукый акт кабул итү һәм «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендәге иң яхшы хезмәткәре» конкурсын үткәрү | + | + | + | + | 32,55 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм жирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен диспансериза цияләүне үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | диспансериза ция үткән муниципаль хезмәткәрләр һәм жирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен ең саны, кеше | 320 | 391 | 400 | 400 | 624,65 (муниципаль бюджет) | 655,94 (муниципаль бюджет) | 655,94 (муниципаль бюджет) |
| 13 | Муниципаль хезмәткәрләр нең эш урыннарында матди-техник жиһазлар урнаштыру һәм аларны модернизация ләү | Башкарма комитетның гомуми бүлеге | 2018-2020 еллар | жирле үзидарә органнары эшчәнлеген мәгълүмати, административ-хуҗалык һәм матди-техник яктан тәэмин итүне оештыру һәм килешүләр булу | + | + | + | + | 1931,55 (муниципаль бюджет) | 2000,0 (муниципаль бюджет) | 2000,0 (муниципаль бюджет) |

- 6 бүлектә «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 11427,84 мең сум күләмендә: 2018 елда – 3809,28 мең сум, 2019 елда – 3809,28 мең сум, 2020 елда – 3809,28 мең сум» сүзләрен «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 11302,98 мең сум күләмендә: 2018 елда – 3684,42 мең сум, 2019 елда – 3809,28 мең сум, 2020 елда – 3809,28 мең сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев